**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2021 Балык Бистәсе штп. № 245пи

2022 елга Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе тәкъдимен карап, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Мәктәпләрдә укучыларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары турында” 2010 елның 6 декабрендәге 1013 номерлы, “Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне оештыруны финанслау нормативларын хисаплап чыгару буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында" 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карарларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына туры китереп КАРАР БИРӘМ:

1.Расларга:

-2022 елга Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын;

- Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларын, әлеге карарның 1

пункты белән расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларына туры китереп, финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Җитәкче Исланов Р. Л.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2021 елның 12 ноябрендәге
245пи номерлы карары белән
расланган

2022 елга Балык Бистәсе муниципаль районында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумнарда | Автотранспорт чарасының бер километр юл узуга ставкасы, сумнарда |
| КАВЗ | 154152 | 38,77 |
| ПАЗ | 153591 | 38,68 |
| ГАЗ «Газель» | 133242 | 31,16 |
| УАЗ | 132789 | 29,69 |
| FIAT | 136630 | 28,02 |
| Peugeot Boxer | 142063 | 27,66 |
| Ford Transit | 142320 | 31,34 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 156063 | 36,63 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 елның 2 декабрендәге
257пи номерлы карары белән
расланган

**Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба- муниципаль хезмәт күрсәтү).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы йөреше нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы йөреше турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган автотранспорт чарасының хисап елында факттагы йөреше буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

1.1. Муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m)$$

анда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m модельле автотранспорт чараларының фактик йөреше, километрларда;

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, бер километрга, сумнарда ;

$NF_{as\,m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясе нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сумнарда;

$M_m$ - m модельле автотранспортчараларының саны, берәмлек;

$m$ -муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләренең атамалары;

$k$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләренең саны.